**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул.Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР БАШЛЫГЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт,
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

2022 елның 24 марты 1номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә кадастр номеры 16:24:170301:775 булган җир кишәрлеге биләгән территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә **КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә кадастр номеры 16:24:170301:775 булган җир кишәрлеге биләгән территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлауларны 2022 елның 25 апреленә 15: 00 минутта, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, 422610, Коммунальная ур., 3. адресы буенча урнашкан Лаеш шәһәре Башкарма комитеты бинасында уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә кадастр номеры 16:24:170301:775 булган җир кишәрлеге биләгән территорияне планлаштыру проекты белән танышу мөмкинлеген Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, 422610, Коммунальная ур., 3. адресы буенча бирергә. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә кадастр номеры 16:24:170301:775 булган җир кишәрлеге биләгән территорияне планлаштыру проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне, язма рәвештә, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, 422610, Коммунальная ур., 3. адресы буенча җибәрергә.

3. Лаеш шәһәре Советына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә кадастр номеры 16:24:170301:775 булган җир кишәрлеге биләгән территорияне планлаштыру проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итү һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Арефьевка йөкләргә.

**Шәһәр башлыгы** **И.Ф.Зарипов**